ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПОЛЯНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.08.2020 ел N 18

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Полянка авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен карау һәм анализлау буенча бердәм тәртип урнаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районы Полянка авыл җирлегенең рәсми сайтында http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль
районының Полянка авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Г.Г. Сибгатуллина

СОВЕТ ПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Спас муниципаль районы Полянка авыл
җирлеге башкарма комитеты карарына кушымта
31.08. 2020 ел N 18

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Полянка авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе

1. Әлеге тәртип "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнгән һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге башкарма комитетына килгән мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшенең сыйфатын яхшырту, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын арттыру максатларында уздырыла.

3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тиешле чорда кергән барлык мөрәҗәгатьләр буенча, шул исәптән язма рәвештә мөрәҗәгатьләр буенча, Спас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү бүлмәсе аша электрон документ рәвешендә, шулай ук гражданнарны шәхсән кабул итү барышында вәкаләтле затлар тарафыннан кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча гамәлгә ашырыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау ел саен гамәлгә ашырыла.

5. Киләсе хисап чорының айның 10 числосына кадәр гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә төзелә.

6. Аналитик белешмәдә гражданнарны шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхсән күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм башка актлар турында (булган очракта) мәгълүмат булырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тиешле чорда алдагы елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Башкарма комитет секретаре ел саен аналитик белешмәне авыл җирлегенең рәсми сайтында "Гражданнар мөрәҗәгатьләре" бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштыруны тәэмин итә.